| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«СТАРОКУВАКСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ИСКЕ КУАК<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |

2024 елның 4 октябре № 22

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Иске Куак авылҗирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2015 елның 26 октябрендәге 9 номерлы карарына (15.10.2018 № 34, от 29.11.2018 № 41, от 01.03.2023 № 2, от 10.04.2023 № 12 үзгәрешләр белән) үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 406 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Иске Куак авылҗирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Иске Куак авылҗирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Куак авылҗирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Куак авылҗирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2015 елның 26 октябрендәге 9 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 1 августындагы 20 номерлы карарын (15.10.2018 № 34, от 29.11.2018 № 41, от 01.03.2023 № 2, от 10.04.2023 № 12 үзгәрешләр белән)үз көчен югалткан дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Иске Куак авылҗирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2015 елның 26 октябрендәге 9 номерлы карарына (15.10.2018 № 34, 29.11.2018 № 41, 01.03.2023 № 2, 10.04.2023 № 12 үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 2 пунктның 1 пунктчасындагы 2 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектларына карата Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектларында, шулай ук салым салу объектларында урнашкан гаражларның һәм машина урыннарының кадастр бәясе аларның һәрберсенә 300 миллион сумнан артык»;

б) карарның 2 пунктындагы 1 пунктчасының 4 абзацын төшереп калдырырга;

в) карарның 2 пунктындагы 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы тарафыннан билгеләнә торган күчемсез мөлкәт объектлары исемлегенә кертелгән салым салу объектларына карата 2025-2027 еллар салым чорларына 1,2 процент һәм 2028 елдан башлап алдагы салым чорларына 2 процент салым салу объектларына карата Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган;

Һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектларына карата 2025 елга 2 процент һәм 2026 елдан башлап алдагы салым чорына 2,5 процент.».

3. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан җирлекнең мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә: Иске Куакавылы, Заварыкин урамы, 36 йорт, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (https://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга

4. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

«Иске Куак авылҗирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе

И.Н.Сушкова